| СОВЕТ САЛИХОВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ БАВЛИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БАУЛЫ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ САЛИХ АВЫЛ ЖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ |
|---|---|

РЕШЕНИЕ КАРАР

12.03.2020 Яңа Чүте авылы № 125

Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы Салих авыл җирлегендә халык алдында тыңлауларны, җәмәгать фикер алышуларын оештыру һәм үткәрү тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакында

Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы Салих авыл җирлегендә яшәүчеләр катнашында җирле әһәмияттәге мәсьәләләр буенча муниципаль хокукый актлар проектлары буенча фикер алышу, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 ел, № 131-ФЗ Федераль закон, Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы, Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы Салих авыл җирлеге Уставы нигезендә, кешенең уңай тормыш шартларына хокукларын үтәү, муниципаль хокукый актлар проектлары буенча фикер алышу максатларында, Баулы муниципаль районы Салих авыл җирлеге Советы

КАРАР ИТӘ:

1. Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы Салих авыл җирлегендә халык алдында тыңлауларны, җәмәгать фикер алышуларын оештыру һәм үткәрү тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакында;
2. Баулы муниципаль районы Салих авыл җирлеге Советының 2018 елның 13 июнендә № 69 кабул ителгән карары «Салих авыл җирлеге муниципаль берәмлегендә халык тыңлауларын, иҗтимагый фикер алышуларны оештыру һәм үткәрү тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакында» үз көчен югалткан дип танырга.
3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга .http://www.pravo.tatarstan.ru) Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы сайтында. http://www.bavly.tatarstan.ru.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотам.
5. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Совет Рәисе
Салих авыл җирлеге башлыгы З. С. Галләметдинов